ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы,
422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

10.12.2025 № 02

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2026 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә белән 2025 елның 10 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 94 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 51 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 51 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пунктының бер өлешендә гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пунктында 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган

акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районы Макуыл авыл җирлегенең Рус Макылы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: П.Е. Карпухин